Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«11» ноябрь 2021 ел № 7

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 8 ноябрендә, 10 ноябрендә, 11 ноябрендә узган: «2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пункты территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган салымны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Авыл эчендәге юлларны, шул исәптән, грунт-вак таш түшәү, салу сезонлы карап тоту һәм, Кәкре Атау торак пунктында төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.

2) Кәкре Атау торак пунктында күперне ремонтлау.

3) Урамнарны яктырту системасын ремонтлау һәм җиһазлау. Яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру.

4) Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

5) Кәкре Күл торак пунктында ял паркын төзекләндерү (сәхнә урнаштыру, территорияне киртәләү, эскәмияләр алу һәм үсентеләр алу)” мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 306 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 214 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 187 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 27 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау торак пункты территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган салымны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Авыл эчендәге юлларны, шул исәптән, грунт-вак таш түшәү, салу сезонлы карап тоту һәм, Кәкре Атау торак пунктында төзелеш контроле өчен түләү белән карап тоту һәм ремонтлау.

2) Кәкре Атау торак пунктында күперне ремонтлау.

3) Урамнарны яктырту системасын ремонтлау һәм җиһазлау. Яктырткычларны алыштыру һәм урнаштыру.

4) Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

5) Кәкре Күл торак пунктында ял паркын төзекләндерү (сәхнә урнаштыру, территорияне киртәләү, эскәмияләр алу һәм үсентеләр алу)” мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кәкре Атау торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева